**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет Шибашинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге Советы**

422886, РТ, Алькеевский район,
с. Русские Шибаши, ул.Мира, д.20
Факс (84346) 75-4-37

422886, ТР, Рус Чиябаш авылы,
Тынычлык урамы, 20 й.
Факс (84346) 75-4-37

РЕШЕНИЕ Рус Чиябаш авылы КАРАР

2022 елның 21 июне 53№

Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге "Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук "Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 01 апрелендәге “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 90-ФЗ номерлы Федераль закон, "Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябре 23 номерлы карар белән расланган "Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук "Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

7 пунктның «в» пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) үз чыгымнары, шулай ук һәр алыш - биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, шулай ук һәр алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балалары тарафыннан белешмәләр тапшыру елыннан (алга таба-хисап чорында) календарь ел дәвамында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең)

13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. Килешү суммасы муниципаль вазыйфаны biләп торучы затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә, муниципаль вазыйфаны биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, санлы валюта алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акчалар чыганаклары турында белешмәләр, законнарда каралган тәртиптә "Интернет"челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла, ә бу мәгълүматлар булмаган очракта, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында аларның мөрәҗәгате буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары тапшырыла.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәгеТатарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга.

Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге Советы Рәисе: И.З.Самигуллин